Әхмәтгалиева, А. "Дөньяның ялтыравык әйберләренә алданмыйм" / А. Әхмәтгалиева; [әңгәмәдәш] А. Гайнуллина // Акчарлак. – 2025. – №17 (30 апрель). – Б. 2-3.



## Бәйрәм белән!



Безнең тормышта күп нәрсә үзгәрсә дә, бу бәйрәм халыкның иң яраткан бәйрәмнәренең берсе булып кала. Өлкән буын кешеләре өчен 1 май – элеккечә, бердәмлек көнен, ә яшьләр өчен – язгы яңарыш, табигать һәм кеше энергиясен символлаштыра.

"Акчарлак" укучыларын Яз һәм Хезмәт бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз! Яшәү көче, күңел тынычлыгы һәм сәламәтлек телибез. Елларда артык күп эшләп ташламагыз, үзегезне саклагыз.

**Редакция**

## МАЙ КИЛӘ

Дөньяны яктыртып,
Кояшлы май килә.
Йөзләрне яктыртып,
Урамда май көлә!

Һәммәбез сагынып
Көттек май килүне –
Китерә ул безгә
Иң бөек Җиңүне!

Бәйрәмнәр еш булмый,
Гел шатлан, гел елмай!
Май килә дөньяга!
Чәчәкле, җырлы май!

Май килә, бәйрәмле
Көннәргә бай булып.
Калыр ул хәтердә
Иң якты май булып!

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

**МАГНИТ "БУРАННАРЫ" КӨТЕЛӘ:**
2, 5, 6,7, 28 май

### СЫНАМЫШЛАР

Май суык булса икмәк уңа.

Яңгырлар еш явып, томан еш төшсә уңышлы елга.

Май яңгырлы булса, июнь коры килә.



Бала вакытында бөтен ишеткәне, күргәне мәктәп белән китап булган кешедән кем чыксын? Укытучылар гаиләсендә туган, ике сеңлесенә дәрес биреп уйнап үскән Айгөл Әхмәтгалиеваның язучы, драматург, журналист, мөгаллимә булуы һич тә гаҗәп түгел. Бүгенге көндә Чаллы театрының әдәби бүлек җитәкчесе дә әле. Паспортында Актаныш районы Иске Сәфәр авылында туган дип язылган. Бала чагы Качкында үткән. Әти-әнисе – Усыдан. Үзе: "Минем туган авылларым өчәү", – ди.

# Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА: "Дөньяның ялтыравык әйберләренә алданмыйм"

**– Айгөл, үзең чыгарган китаплардан балачак исе киләме? Китап арасында үстем дигәнгә сорыйм.**

– Безнең әни башта мәктәп китапханәсендә эшләде. Районнан арыш капчыгы белән (мин аны бәрәңге капчыгы дим) яңа китаплар алып кайта. Аны китапханә идәненә бушаталар. Шушы яңа китап исе бүгенге көнгә кадәр борынымнан китми торган кадерле ис булып тора. Өйдә дә китапханәбез шактый бай булды. Үз китабым чыкканга сөенү хисе ничек зур булса да, кызганыч, хәзер балачакта тойган ул исне тоймыйм. Китап исе үзгәрде микән, әллә тормыш безне үзгәрттеме. Бала вакыттагы кебек сөенә белү, тоемлау сәләте тоныклана микән.



Усы авылында, әти-әнисе, сеңелләре белән.

**– Сеңелләрең кайда?**

– Уртанчыбыз – Актанышта, күрше авылда мәктәптә эшли. Тарих укыта. Кечкенәсе – Чаллы янында Круглое Поледа. Газетада эшли. Икесе дә иҗади кешеләр, бик матур язалар. Әмма кече сеңлебез үзен күбрәк гаиләсенә, өч кызына багышлый.

**– Әти-әниләрең ничә яшьтә, саулыклары ничек?**

– Аллага шөкер, исән-саулар, Качкында яшәп яталар. Әнигә – 71, әтигә 81 яшь булды. Без кайтканда капканы ике якка каерып ачып каршы алулары минем өчен иң олы бәхетләрнең берсе.

**– Әниең белән больница юлында күп йөрергә туры килгәнен әйткән идең.**

– Әни гаиләгә килгән сынаулар турында сөйләгәнне бик хупламый. Әйе, сәламәтлеккә бәйле мәшәкатьләр булып алды. Беләсеңме, без әни белән сөйләшкәндә гел бер фикердә туктала-быз. "Аллаһ Тәгалә һәркемгә тиешле го-мерне билгеләгән. Син шуны тәкъдир ди кабул итәсең икән һәм барына рәхмәтле булып, килгән сырхаулардан шифасын сорыйсың икән, барысы да яхшы була-чак. Шуңа ышан һәм Аллаһка таян", – дигән девизыбыз барлыкка килде. Ничә еллар дәвамында байтак кына табибла янында булдык, чыннан да шактый авыр сынаулар кичердек һәм гел догада бул-дык. Намаз саен: "Кодрәтле Аллам, минем әнкәемә дә Әюп пәйгамбәргә күрсәткән могҗизаңны күрсәтсәң иде", – дип сорыйм. Бүген барлыгыңа һәм Аллаһ Тәгаләнең биргәненә сөенә белү яшәргә көч бирә гомерне озынайта, үзеңә ышаныч тудыра дип уйлыйм. Төптән уйласаң, тормышның һәр көне – көрәш. Авырулар белән, үз үзең белән. Кемдер яу кырында көрәштә

**– Иҗатыңда дин темасы нинди уры ала?**

– Һәр әсәремдә телимме, теләмимме дин темасына үз каланчамнан, үзем аңлаганча якын киләм икән. Җәли хәзрәтнең вәгазьләрен шундый ятратам

үзен бик нык хөрмәт итәм. Китапларым басылып чыкканнан соң ул шалтыратып фикер белдерүе дә үзе бер күрсәткеч. Сүз арасында, төрле катламнарга ышереп кенә биргән фикерне дә тоеп алып, шуңа үзенең мөнәсәбәтен, автор булырак миңа киңәшләрен җиткергәне өчен рәхмәтле мин аңа. "Таллы күлдә былбыл бар" дигән әсәремдә төп идея итеп, халыкның мул тормышта, рәхәт яшәвенең сере – авылда кешенең мәчетле, ихлас, иманлы булуында, дигән фикерне үткәрергә тырышкан идем. "Кечке таң" дигән повестьне язганда эпиграф итеп "Бәкара" сүрәсеннән бер өзек язып куйдым. "Аллаһтан кайта торган көннән куркыгыз" дип. Шушы девиз повестьнең буеннан буена кызыл җеп булып барды. "Туташ"та да тарихи персонажларны керткәндә дини тәрбия алган яшьләрнең яңа тормыш төзибез дип революцион рухта яшәүләре дөресме, дигән сорауга җавап табарга тырышканмын икән.

**– "Икән" дисең... Бу сорауга җавап тапмадыңмы әле?**

– Бу сорауга өздереп җавап бирсәм, үз өстемә гөнаһ алырмындыр. Дөресен әйткәндә, мин хак җавапны белмим. Романда Сәхипҗамал Волжскаяның бөтен фаҗигале язмышын яктыртып бардым. Һәм ирексездән, романны тәмамлаганда героиняның бәхетсезлекләренең башы әти-әнисенең күз яшьләреннән башланмадымы икән, дигән уйга калдым. Сизгер укучы романда минем җавапны тоя ала.

**– Ирең дә намаздагы кешеме? Кайсы өлкәдә эшли?**

– Ирем Флюс намазда, Аллаһның барлыгын белеп, танып яши торган кеше, шөкер. КАИны тәмамлады, аның өлкәсе – техника, радио, компьютерлар.

**– Очрашуларга, бөтен чараларга бергә йөрисезме?**

– Әйе, ул мине үзе йөртә. Чаллыда мин машинада йөрим. Ә Казанга, башка шәһәрләргә, күрше төбәкләргә барасы булса, ул алып бара. Чөнки мин машинада утырганда да, күзем юлда, кулларым рульдә булганда да уйларым бүтән җирдә булырга мөмкин. Язылып бетмәгән әсәр, андагы геройларым белән башка ясылыкта йөрим. Ирем шуны белә, аңлый һәм "синең өчен борчылып торганчы, үзем алып барып кайтам" ди. Кайтканда очрашуны сүтеп җыябыз, киңәшләрен бирә ирем, фикерләрен әйтә. Флюскә: "Синнән кыйммәтле бүләкләр, алтын алкалар, туннар сорамыйм. Әйдә, китап чыгарыйк әле", – дим. Язган әйберең не халыкка җиткерәсе килә бит. Узган ел 500 битлек пьесалар китабымны, "Бик"не чыгардык.



Әлфия Авзалова белән.

**– Китап чыгаруга киткән чыгымнар аны сатудан капланамы?**

– Чыккан тиражны сатып бетерсәң, капланырга мөмкин.

**– Син аралашканда шундый йомшак, тыныч кеше булып тоеласың. Ә чынбарлыктагы Айгөл нинди?**

– Чын Айгөл нәкъ син күргән Айгөл инде ул, икейөзләнмим. Үземә тимәсәләр, гаделсезлеккә юлыкмасам, мин чыннан да йомшак, сабыр. Әмма кирәк чакта алыштырып куйган кебек була алам. "Мин" дигән әйбер миндә юк. Нindидер уңышларга, казанышларга ирешәм икән, болар минеке түгел. Аллаһ Тәгаләнеке ул. Аллаһ эшләргә саулык, күз, мөмкинлек, илһам бирмәсә, син бернәрсәгә дә ирешә алмыйсың. Бары тик аның рәхмәте белән генә дим. Кайвакыт килеп утырасың, урындыгың да бар, язарга темаң да, компьютерың да, вакытың да... һәм экранга карап утырасың инде менә, язылмый. Ә кайвакыт әйтеп торган кебек үзеннән-үзе языла.

**– Ялкаулыкны, булдыксызлыкны акларга була түгелме соң болай? Аллаһ Тәгалә бирмәде дисең дә, бетте-китте.**

– Кызык кына борып куйдың әле син. Ул бирә, биргән мөмкинлеген тиешенчә файдаланабыз микән...

**– Синең ялсыз эшләгәнеңне аңладым инде.**

– Әйе, син хаклыдыр. Әмма тырышлык белән аклану арасында барыбер аерма бар. Мин ял итә белмим дә, ял итәргә яратмыйм да. Ярты сәгать буш вакыт булса, үземә урын тапмыйм. Диңгезгә баргач та тыныч кына таралып ята белмим. Башта төрле фәлсәфи уйлар, анализлар, идеяләр кайный, вакытны әрәм итәсе килми. Гомер шундый кыска бит.

**– Диңгез буена каләм белән барасыңмы, телефонга язасыңмы анда? Хыялыйлык үзең белән каламы?**



"Язганны халыкка җиткерәсе килә".

– Бөтен әйберем үзем белән. Былтыр хәтта үзем белән Шәйхи Маннурның кирпеч калынлыгы "Муса" романын алып киттем. "Хәл бу ки... Муса Җәлил" проектын әзерләгән чак иде. Менә шулай эшләгәндә мин үземнең яшәвемне тоям, рәхәтлек алам.

**– Балаларың турында да бер-ике сүз.**

– Алар зурлар инде, шөкер. Улым да, кызым да Казанда яшиләр.

"Җеннәребез килешмәгән кеше белән ихлас арашала алмыйм. Йомылып калам", – дип серен ачты Айгөл. "Капка" спектаклен бергә карадык. Шунда күзләре яшьләнгәнен күреп гаҗәпкә калдым. Ул аны үзе язган, ничә караган бит, югыйсә.

**Альбина ГАЙНУЛЛИНА**

## Шулай дип язганнар...

* * *

**Зәринә Асылкаева,** *җырчы:* "Аңлыйм, бу сүзләремне укучыларның кайсыдыр өлеше кабул итмичә, начаррак комментарийларын калдырыр. Ләкин бу – минем фикерем: булачак иремнең машинасы да, яшәргә урыны да булырга тиеш, мин яшәгән йортка кермәс бит инде ул?"

*"Интертат"*

* * *

"Авыллар картая. Бабайларсыз картая. Картлык белән бергә авылга матриархат та килә. 170ләп кеше яши торган безнең авылда бүген яше 60тан арткан нибары 17 ир-ат бар! Аларның да берничәсе яңарак алтмышын тутырган, нибары өчесе 80не үткән. Чагыштыру өчен: 60тан өлкән әбиләребез – 35, шуларның унысы – сиксәнне, өчесе, шөкер, инде 90 чиген үткән..."

*"Ватаным Татарстан"*

* * *

**Ален Делон,** *француз актеры:* "Мин инде бу тормыштан берни дә ала алмыйм. Барысын да күрдем, барысын да кичердем. Бүгенге чордан күңелем болгана. Бүгенге кешеләрне күралмыйм. Бөтенесе дә ясалма. Беркем дә биргән вәгъдәсен үтәми, беркемгә дә хөрмәтем юк. Беренче урында акча гына тора. Бу дөньяны берни̇нди үкенүләрсез калдырып китәм..."

*"Пари-Матч" журналы*